КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 25 гыйнвар г.Казань № 40

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 ел, 23 декабрь, 1052 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 ел, 23 декабрь, 1052 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 22 февраль, 128 нче; 2013 ел, 7 ноябрь, 860 нчы; 2015 ел, 26 август, 623 нче; 2016 ел, 17 октябрь, 749 нчы; 2016 ел, 31 октябрь, 800 нче; 2017 ел, 10 май, 269 нчы; 2018 ел, 30 июль, 613 нче; 2018 ел, 7 ноябрь, 983 нче; 2018 ел, 19 декабрь, 1179 нчы; 2018 ел, 29 декабрь, 1302 нче; 2019 ел, 13 июль, 577 нче; 2019 ел, 19 ноябрь, 1057 нче; 2020 ел, 6 март, 178 нче; 2020 ел, 19 май, 405 нче; 2020 ел, 2 июнь, 458 нче; 2021 ел, 10 апрель, 238 нче; 2022 ел, 10 май, 427 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3.17 пунктның 1 пунктчасындагы беренче һәм икенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) түбәндәге эшчәнлек төрләрен лицензияләү (лицензияләр бирү, лицензия алырга теләүчеләрнең лицензия таләпләренә туры килүен бәяләү, «Кайбер эшчәнлек төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очракларда лицензияләр реестрына үзгәрешләр керткәндә лицензия алучыларның лицензия таләпләренә туры килүен бәяләү, лицензияләрне гамәлдән

чыгару, Министрлык тарафыннан бирелгән лицензияләр реестрларын булдыру һәм алып бару, лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү, хәбәрнамәләр һәм лицензияләү барышында файдаланыла торган башка документлар формаларын раслау, шулай ук кызыксынучы затларга лицензияләү мәсьәләләре буенча мәгълүмат бирү (бу мәгълүматтан файдаланучылар тарафыннан рәсми сораулар җибәрелә һәм соратыла торган мәгълүмат алына алган электрон почта адреслары күрсәтелгән әлеге мәгълүматны Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны кертеп) өлешендә):

а) медицина эшчәнлеге («Сколково» инновацион үзәге территориясендә медицина оешмалары һәм хосусый сәламәтлек саклау системасына керә торган башка оешмалар, башкарма хакимият федераль органнары ведомствосы буйсынуындагы оешмалар, башкарма хакимият федераль органнарының федераль закон нигезендә хәрби һәм аңа тигез булган хезмәт каралган оешмалары, шулай ук югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырыла торган әлеге эшчәнлектән тыш);»;

5.1 пунктның беренче абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Министр вазыйфасына билгеләүне һәм әлеге вазыйфадан азат итүне килештерү Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин